| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**23.05.2025** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 1433** |
|---|---|---|

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы милкендәге арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәт өчен һәм мондый мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан сатып алына торган түләүне кичектереп түләү срогын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, 2007 елның 24 июлендәге «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 209-ФЗ номерлы Федераль закон, 2008 елның 22 июлендәге «Дәүләт яки муниципаль милектә булган һәм арендага алынган күчемсез мөлкәтне читләштерү үзенчәлекләре һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 159-ФЗ номерлы федераль закон, 2010 елның 21 гыйнварындагы «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ**:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы милкендәге арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәт өчен һәм мондый мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан сатып алына торган түләүне кичектереп түләү срогы күчемсез мөлкәт өчен сигез ел һәм күчемле мөлкәт өчен өч ел тәшкил итә.
2. Арендалана торган мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан сатып алына торган арендаланучы мөлкәт өчен түләү тәртибен (берьюлы яисә кичектереп түләү), шулай ук әлеге карарның 1 пункты нигезендә билгеләнгән чикләрдә кичектереп түләү срогын сайлау хокукы кече яисә урта эшкуарлык субъектына карый.
3. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы милкендәге арендалана торган күчемле һәм күчемсез мөлкәт өчен һәм мондый мөлкәтне сатып алуга өстенлекле хокукны гамәлгә ашырганда кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан сатып алына торган түләүне кичектереп түләү срогын билгеләү турында» 2024 елның 25 декабрендәге 4433 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарны «Зеленодольская правда» газетасында, шулай ук Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының (http://pravo.tatarstan.ru ) рәсми порталында, Татарстан Республикасы муниципаль

берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат (www.zelenodolsk.tatarstan.ru ) сайтында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфасын башкаручы А.В. Старостин